# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы
Якты Күл авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

**31.10.2020 ел** **№1**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендә кабул ителгән 45- ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2020 елның 31 октябрендә узган Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Якты Күл авыл җирлегендә халык җыены

**КАРАР ИТТЕ:**

«Сез, 2021 елда, Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Учук» бәйрәмнәрен үткәрүгә бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу);
- Якты Күл авылында җирлекне яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру);
- Якты Күл авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту: (Якты-Күл урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм/яки ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Якты Күл авылында балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре);
- Якты Күл авылы зиратында контейнер мәйданчыкларын төзү (контейнер, киртә өчен материаллар сатып алу, коймалар әзерләү һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары төзү (нигез, коймаларны урнаштыру);
- Җирлек территориясеннән каты коммуналь калдыкларны чыгару.

РИЗА КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Җыенда, сайлау хокукына ия булучы катнашучылар исемлегендә 57 гражданнар җыенында катнашучы теркәлгән, халык җыенда катнашып тавыш биргән гражданнар саны - 36 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«РИЗА» позициясе өчен 34, «КАРШЫ» позициясе өчен 2 гражданнар җыенында катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Азнакай муниципаль районы Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл авылында халык җыенын узган дип, халык җыены нәтиҗәләре- гамәлдә (дөрес) дип танырга.

2. Түбәндәге сорау буенча карарны кабул итәргә: «Сез, 2021 елда, Үчәлле авыл җирлеге Якты Күл торак пункты территориясендә 1 төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә, 2 группа инвалидлар өчен 250 сум күләмендә бер тапкыр түләүне киметеп, үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү («Яңа ел», «Җиңү көне», «Сабантуй», «Халыкара өлкәннәр көне», «Учук» бәйрәмнәрен үткәрүгә бүләк һәм сувенир продукциясен сатып алу);

- Якты Күл авылында җирлекне яктырту һәм урамнарны яктырту буенча хезмәт күрсәтү (лампалар, яктырткычлар, электр товарлары һәм махсус җайланмалар сатып алу һәм алыштыру);

- Якты Күл авылында җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын карап тоту: (Якты Күл урамы буенча юлларга вак таш җәю (сатып алу һәм/яки ташу, вак таш җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- Җирлек территорияләрен төзекләндерүне оештыру (Якты Күл авылында балалар өчен уен мәйданчыгы сатып алу һәм урнаштыру, юлларны кардан чистарту буенча чит оешмалар хезмәтләре);

- Якты Күл авылы зиратында контейнер мәйданчыкларын төзү (контейнер, киртә өчен материаллар сатып алу, коймалар әзерләү һәм урнаштыру, контейнер мәйданчыклары төзү (нигез, коймаларны урнаштыру);

- Җирлек территориясеннән каты коммуналь калдыкларны чыгару.

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә, Үчәлле авыл җирлеге мәгълүмати стендында (Россия, Татарстан Республикасы, Азнакай районы, Үчәлле авылы, Совет урамы, 51 нче йорт, Якты Күл авылы, Якты Күл урамы, 15 йорт), Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында (http://aznakaevo.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Үчәлле авыл җирлеге башлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Азнакай муниципаль районы
Үчәлле авыл җирлеге Башлыгы Г.М.Төхвәтуллина